ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ
Боерык

Казан шәһәре

09.03.2023

№ 90 - од

«Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогы бирү турында шартнамә төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 елның 21 декабредәге 179-од номерлы Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларын «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында» 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында боерам:

«Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогы бирү турында шартнамә төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 елның 21 декабредәге 179-од номерлы Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе боерыгына (Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенең 2017 елның 28 февралендәге 23-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсен төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясе турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсен төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясен оештырырга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсен төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясенең кушымта итеп бирелә торган Эшчәнлек тәртибен расларга.»;

Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогы бирү турында шартнамә төзү хокукына конкурс үткәрү Комиссиясе эшчәнлеге тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенең 2015 елның 21 декабрендәге 179-од номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 09.03.2023 90 -од номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсен төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясенең Эшчәнлек тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсен төзү хокукына конкурс үткәрү комиссиясенең (алга таба – Комиссия) эшчәнлек кагыйдәләрен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясенең балыкчылык һәм су биоресурсларын саклау өлкәсендәге халыкара килешүләренә, шулай ук әлеге Тәртипкә таяна.

Комиссия үз вәкаләтләрен «Сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсе төзү хокукына конкурс үткәрү һәм мондый шартнамәне төзү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 14 апрелендәге 264 номерлы карары белән расланган Сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыру өчен балык тоту участогыннан файдалану шартнамәсен төзү хокукына конкурсны оештыру һәм үткәрү кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) һәм әлеге Тәртипкә ярашлы рәвештә гамәлгә ашыра.

3. Комиссия составына Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Балыкчылык буенча Федераль агентлыкның Идел-Кама территориаль идарәсе вәкилләре һәм кызыксынган федераль башкарма хакимият органнарыннан (аларның территориаль органнарыннан) берәр вәкил керә (килешү буенча).

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар Комиссия әгъзалары була алмый, шул исәптән:

конкурста катнашу өчен гариза (алга таба – гариза) биргән затлар яки гаризалар биргән оешмалар штатында торучылар;

Россия Федерациясенең Монополиягә каршы законнары нигезендә гариза биргән оешмаларның, шул исәптән әлеге оешмаларда катнашучыларның (акционерларның), аларның идарә органнары әгъзаларының һәм аларның

кредиторларының аффилирланган затлары булган затлар.

Комиссия составында күрсәтелгән затлар ачыкланган очракта, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Конкурсны оештыручы) аларны шунда ук конкурс нәтиҗәләре белән кызыксынмаган һәм гариза итүчеләр йогынты ясый алмый торган башка затлар белән алыштырырга тиеш.

Комиссия рәисе итеп Конкурсны оештыручы вәкиле билгеләнә.

4. Комиссия эшчәнлегенең төп принциплары:

а) гариза бирүчеләр өчен конкурста катнашу өчен тигез шартлар булдыру;

б) намуслы көндәшлек;

в) су биологик ресурсларын нәтиҗәле куллану;

г) конкурсны үткәрү турында мәгълүматның файдаланырлык булуы, һәм аны үткәрүнең ачыклыгын тәэмин итү.

5. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

а) гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул итә;

б) конкурста җиңүчене билгели;

в) конкурс үткәрү белән бәйле башка гамәлләрне башкара.

Күрсәтелгән функцияләрне гамәлгә ашыру максатыннан Комиссия түбәндәге гамәлләрне башкара:

а) гариза бирүчеләрне Кагыйдәләрнең 12 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүләрен, шулай ук гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның Кагыйдәләрнең 27 пунктына ярашлы рәвештә дөреслеген тикшерә;

б) конкурсның теләсә кайсы стадиясендә гариза бирүченең «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә затлар төркеме составына керү фактын тикшерә;

в) гаризаларны теркәү өчен җаваплы кешене билгели;

г) гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү ачылганнан соң бер эш көне эчендә Конкурсны оештыручыга мөрәҗәгать итә, ул ведомствоара сорату аша гариза бирүчегә карата Кагыйдәләрнең $28^1$ нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматны сората;

д) гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачу алдыннан гына, әмма хәбәрнамәдә һәм конкурс документларында күрсәтелгән вакыттан да иртәрәк түгел, гаризалар белән конвертларны ачуда һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачуда катнашучы затларга гариза бирү, конвертларны ачу һәм гаризаларга керүне ачу процедурасы башланганчы гаризаны үзгәртү яки кире алу мөмкинлеге турында игълан итә;

е) гаризалар белән барлык конвертларны ача һәм Конкурс оештыручысына аларны ачу һәм аларга керү процедурасы башланганчы килгән гаризаларга керү мөмкинлеген ача. Гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачу вакытында гаризалар белән конвертлары ачыла яисә гаризаларына керү мөмкинлеген ачыла торган һәр гариза бирүченең исеме (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) (шәхси эшкуар өчен), конкурс документларында каралган документларның булу-булмавы турында белешмәләр, балык тоту участогыннан файдаланган өчен Татарстан Республикасы

бюджетына түләү күләме турында тәкъдим, шулай ук Кагыйдәләрнең 28 пунктында каралган документлардагы мәгълүматлар игълан ителә һәм гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачу беркетмәсенә кертелә;

ж) гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачу вакытында, гариза бирүче (аның вәкиле) Комиссиягә гаризада һәм аңа кушып бирелә торган документларда булган мәгълүматларны аңлатманы тапшыра, алар Комиссия тарафыннан гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачу беркетмәсенә кертелә. Комиссия гариза бирүчеләргә өстәмә таләпләр куярга һәм конкурс документларында каралган таләпләрне үзгәртергә хокуклы түгел;

з) гаризалар белән конвертларны ачу һәм гаризаларга керү мөмкинлеген ачу процедурасын аудиоязмалый;

и) гаризаларның конкурс документларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли;

к) гаризаларны карау нәтиҗәләре нигезендә, Кагыйдәләрнең 15 пунктында каралган нигезләр буенча гариза бирүчеләрне конкурста катнашуга кертү яки кертүдән баш тарту турында карар кабул итә;

л) гаризаларны карау беркетмәләрен рәсмиләштерә, ул утырышта катнашучы комиссия әгъзалары тарафыннан гаризаларны карау тәмамланган көнне имзалана. Гаризаларны карау беркетмәсе имзаланган көнне конкурсны оештыручы тарафыннан рәсми сайтта урнаштырыла;

м) гаризаларны карау беркетмәсенә кул куелганнан соңгы бер эш көне дәвамында Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар турында конкурста катнашырга кертелмәгән гариза бирүчеләргә гариза бирелгән формада хәбәрнамәләр җибәрә. Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша электрон документ рәвешендә гариза бирү мөмкинлеге гамәлгә ашырылганнан соң, һәм гариза бирүчеләр аларны кулланган очракта, гаризаларны карау беркетмәсенә кул куелганнан соңгы бер эш көне дәвамында Комиссия кабул иткән карар турында хәбәрнамә, күрсәтелгән мәгълүмат системаларыннан файдаланып, гариза бирүчеләргә җибәрелә;

н) әгәр дә бер генә гариза бирүчегә конкурста катнашырга рөхсәт ителгән булса, гаризаларны карау беркетмәсенә имза салганнан соң 10 эш көне эчендә әлеге гариза бирүчегә шартнамә проектын тапшыра;

о) шартнамә төзүнең иң яхшы шартларын ачыклау максатыннан, билгеләнгән тәртиптә гаризаларны һәм аңа кушылган документларны бәяләү һәм чагыштыруны гамәлгә ашыра;

п) гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру нәтиҗәләре нигезендә һәр гаризага (башкаларына карата бәяләү критерийлары суммасы кимү тәртибендә) тәртип номеры бирә;

р) гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсен алып бара;

с) гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру һәм конкурс нәтиҗәләрен чыгару

көнендә Комиссиянең утырышта катнашучы барлык әгъзалары гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсенә имза салалар;

т) конкурсны Оештыручыга гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсен ике нөсхәдә тапшыра.

6. Комиссия рәисе (ул булмаган очракта – аның урынбасары) Комиссия утырышларын үткәрә, процедура мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә һәм конкурска йомгак ясый, Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышының урыны, көне һәм вакыты турында вакытында һәм тиешенчә хәбәр итә.

Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия составының гомуми санынннан яртысыннан артыгы булса, хокуклы дип санала.

7. Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия.

Тавыш биргәндә, Комиссия әгъзалары кабул ителгән карарга «риза» яки «каршы» тавыш бирәләр. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

8. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхсән катнашалар һәм Комиссия утырышларының беркетмәләренә имза салалар.